**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Олы Елга авыл җирлеге Советы**

**КАРАР № LXI-1**

Олы Елга авылы 2024 елның 26 декабре

**2025 елга һәм 2026 – 2027 еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджеты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 10 өлешенең 2 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 12 һәм 14-15 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 маддәсендәге 8 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Уставының 19 маддәсендәге 2 өлешенең 3 пункты һәм 70,71 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ:**

**1 маддә.**

**1.** 2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 5156,98 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының фаразлана торган гомуми күләмен 5156,98 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум итеп.

**2.** 2026 елга һәм 2027 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2026 елга 5437,00 мең сум һәм 2027 елга 5691,8 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының фаразлана торган гомуми күләмен 2026 елга 5437,00 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 106,73 мең сум итеп, 2027 елга 5691,8 мең сум, шартлыча расланган чыгымнарны 87,28 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2026 елга 0,0 мең сум, 2027 елга 0,0 мең сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына бюджет

кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**2 маддә.**

**1.** 2025 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

**2.** 2026 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

**3.** 2027 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

**3 маддә.**

**1.** Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджетында әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына фаразланган керем күләмнәрен исәпкә алырга.

**4 маддә.**

**1.** 2025 елга һәм 2026 – 2027 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан маддәләре һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

**2.** 2025 елга һәм 2026 – 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджетының 2025 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелүче бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 10,00 мең сум күләмендә, 2026 елга 13,0 мең сум күләмендә, 2027 елга 15.0 мең сум күләмендә расларга.

**5 маддә.**

Бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләү һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү буенча вәкаләтләрне үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында авыл җирлекләре бюджетларына Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан алына торган субсидия күләмен 2025 елга 2540,10 мең сум, 2026 елга 2782,70 мең сум, 2027 елга 2989,40 мең сум күләмендә.расларга.

Авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга авыл җирлекләре бюджетларына Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләр күләмен 2025 елга 25,40 мең сум, 2026 елга 8,6 мең сум, 2027 елга 8,6 мең сум итеп расларга.

**6 маддә.**

1. Җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга авыл җирлекләре бюджетларына Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенция күләмен 2025 елга 182,98 мең сум, 2026 елга 200,10 мең сум, 2027 елга 207,30 мең сум итеп расларга.

**7 маддә.**

**1.** Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2025 елда һәм 2026 – 2027 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**8 маддә.**

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешү нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

**9 маддә**.

Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар буенча түләү өчен бирелгән 2025 елның 1 гыйнварына калган акчалары, әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2025 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмаган күләмдә 2026 елда, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

**10 маддә.**

Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**11 маддә.**

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы: Мингалиев И.Н.